# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Кук-Тәкә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**15 ноябрь 2021 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 15 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2 нче төркем инвалидлар өчен түләүне киметеп, 200 сум күләмендә калдырып, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Кук-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) Кук-Тәкә авылында зират коймаларын ясатып урнаштыру;

2) Кук-Тәкә авылының М.Җәлил урамы, Яшьләр урамы зиратларында контейнер мәйданчыклары һәм аларга киртәләр урнаштыру өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыкларын һәм аларның нигезен урнаштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 231 кеше кертелгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 161.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 152, «КАРШЫ» » позициясе өчен 9 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:
“Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2 нче төркем инвалидлар өчен түләүне киметеп, 200 сум күләмендә калдырып, Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Кук-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) Кук-Тәкә авылында зират коймаларын ясатып урнаштыру;

2) Күк-Тәкә авылының М.Җәлил урамы, Яшьләр урамы зиратларында контейнер мәйданчыклары һәм аларга киртәләр урнаштыру өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыкларын һәм аларның нигезен урнаштыру.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева